**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Кырык Садак авылында гражданнар җыены карары**

20.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Кырык Садак авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Кырык Садак авыл җирлегенең Кырык Садак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Кырык Садак авылында кышкы чорда юлларны тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), юлларны ремонтлау юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Кырык Садак авыл җирлегенең Кырык Садак авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кырык Садак авыл җирлеге башлыгы _________ В.Ф.Шаһиева

Халык җыены секретаре _________ Ф.Г.Миңнегалиева